| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2025 Бима авылы № 12

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитетының 28.02.2013 елның 7 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә тиешенчә эш итү, җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 28.12.2020 елның 2314 номерлы карары, «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында» РФ Хөкүмәтенең 14.03.2024 елның 300 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башкарма комитетының 28.02.2013 елның 7 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыны турында мәгълүматны кулланучыларга әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән җиткерергә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында **http://pravo.tatarstan.ru** веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында **https://agryz.tatarstan.ru** веб-адресы буенча урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында

халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Бима авыл
җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Э.И. Михайлов